УДК 94(=512.145):314.74

***Окан Таһир***

## ФИНЛЯНДИЯ ИСЛАМ ҖӘМГЫЯТЕ[1]

Статья освещает историю и деятельность Общества татар Финляндии, объединяющего представителей Исламского общества Финляндии в Хельсинки и Общества мусульман Тампере, организованного в 1943 г. Показаны пути успешной интеграции татар в финское общество, подробно анализируется опыт совместных социальных и культурных практик.

**Ключевые слова:** Общества татар Финляндии, татарская диаспора в Финляндии, интеграция татар в иноязычной и инорелигиозной среде.

**Финляндиядәге татар азчылыгы бу ил шартларына тулысынча интеграцияләшкән.** Алар, эшчән ватандашлар буларак, Финляндия тормышына тиз җайлашалар, шул ук вакытта үз җәмгыятьләрен дә саклап калалар. Татар җәмәгатьчелеге читтән ярдәм алырга теләми, үз тотрыклылыгы аркасында яхшы биналар били, ике зиратны тәртиптә тота алалар. Бу – аларга яңа килеп кушылган мөселман иммигрант төркемнәр өчен үрнәк булып тора.

### Кереш

Татар җәмгыяте Финляндиянең тарихи һәм милли азчылыкларын берләштергән җәмәгать оешмаларының берсе булып санала. Бүгенге көндә Финляндиядә чыгышлары белән төрки булган 700 гә якын мөселман татар кешесе яши, аларның күпчелеге (600 гә якыны) Финляндиядә электән яшәп килгән ислам җәмгыятенең (Suomen Islam-seurakunta) әгъзасы булып тора, ә 100 кеше, 1943 елда Тампере шәһәрендә оешкан ислам җәмгыятенә тупланган. Бу җәмгыятьләрнең әгъзалары, нигездә, Патша Россиясе заманында Идел буендагы Түбән Новгород губернасының фин-угор, мордва һәм руслар белән күрше булган татар авылларыннан чыккан татарлар. Алар, кечкенә күләмдәге җирләргә ия буларак, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгәннәр, ләкин торабара, чәчүлек җирләре кимеп файда китерми башлагач, авыл хуҗалыгы белән бергә сәүдәгәрлек өлкәсендәге эшчәнлекләрен дә башлап җибәрәләр. Әкренләп аларның сәүдәгәрлек сәфәрләре тимер юл буйлап Санк-Петербургка, хәтта Териоки (бүгенге Зеленогорск) аркылы Бөек Фин-

[1] 2017 ел Финляндия бәйсезлегенең 100 еллыгы уңаеннан Финляндия милли азчылыклар хокукларын саклау төркеме 2016 елның азагында «National Minorities in Finland a Richness of Cultures and Languages» исемле җыентык бастырып чыгарды. Китапта Финляндиядә яшәүче төрле милли азчылыкларның көнкүреше һәм тормышы турында мәгълүматлар бирелгән. Биредә шулар арасыннан татар азчылыгын тәшкил итүче Финляндия ислам җәмгыяте турындагы мәкаләнең татар теленә иректе тәрҗемәсе тәкъдим ителә.

ляндия кенәзлегенә һәм Выборгка кадәр барып җитә.

Иң башта татарлар читкә йөреп һәм базарларда сату-алу белән шөгыльләнгәннәр һәм, озак та үтми, үзләренең сату урыннарын да булдырганнар. Сәүдәгәр татарлар шәһәр һәм район үзәкләрендә тукыма сату, тегү һәм күрек ясау үзәкләре ачканнар. Тотрыклы керем татар гаиләләренең яхшы яшәвен гарантияләгән. Сәүдәдә алар элеккеге чикләрен киңәйтә баралар, илләрара аралашуга һәм яңа мәдәни бәйләнешләргә омтылалар. Шулай итеп, гасырлар чигендә илдә индивидуаль һәм гаиләви рәвештә кечкенә, әмма бердәм мәдәни җәмгыять оеша башлый. Финляндиягә күчеп килгән татарларга тормышларын үз илләрендәгечә дәвам итү мөмкин булмый, алар моны яхшы аңлыйлар һәм фин җәмгыятенә бик тиз һәм органик рәвештә җайлашалар. Ана телләренең корылышы һәм тавыш системасы фин теленә охшаш булу сәбәпле татарлар яңа телне бик җиңел өйрәнәләр.

## Уртаклык

Татарлар, бәйсез Финляндия ватандашларына әверелеп, фин җәмгыяте үсешенә хезмәт итә башлыйлар һәм фин мәдәниятенә интеграцияләшәләр, ләкин шул ук вакытта хәтта бишенче буында да үз мәдәни үзенчәлекләрен саклап кала алдылар. Моңа ирешүнең сәбәбе нәрсәдә соң? Беренче һәм икенче буын вәкилләре хезмәт сөючәнлек, ихтыяр көче һәм үзара бердәмлек нәтиҗәсендә үз җәмәгать оешмаларын төзү өчен ныклы матди һәм рухи нигез булдырдылар. Бу җәмәгать оешмасы тарафыннан хупланган бурычларны тормышка ашыру, нигездә, гаиләгә йөкләнә. Гореф-гадәтләрне саклау яшьләргә үз тамырларын, кемлекләрен белеп үсәргә һәм үзүзләрен бәяли белергә ярдәм итә. Гаилә һәм туганнар белән булган тыгыз бәйләнеш бердәмлек һәм ышанычлылык тойгысын ныгыта. Шулай да татар мәдәни мирасын, милли йолаларны саклап калу, балаларны милли рухта тәрбияләү күп көч куюны таләп итә.

Соңгы йөз елда татарлар үз мәдәниятләре белән бергә финнәр казанышларын да үзләштерделәр. Ахыргы чиктә алар Финляндияне үз ватаннары дип кабул иттеләр. Финляндиянең бәйсезлеге урнашкан көннән башлап, татар ислам җәмгыяте әгъзалары фин халкы белән бергә илнең күтәрелеш һәм авыр елларын уртак кичерде. 1939 һәм 1940 еллар кышында барган сугышларда татарлар җәмгыятеннән 156 ир-ат һәм 21 хатын-кыз Финляндия бәйсезлеген һәм мәнфәгатьләрен яклап катнашты, шуларның 10 сы һәлак булды.

Фин шәхесе балаларның урамдагы уеннарында һәм фин уен төркемнәрендә формалаша башлый. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә һәм гимназияләрдә балалар уку, мәктәп дуслары һәм аларның гаиләләре белән аралашу аркылы фин мәдәнияте, җирле халыкның гореф-гадәте белән дә якыннан таныша. Эшчәнлек нигезләре университетларда, институтларда, һөнәри һәм техник училищеларда салынып, кешенең тормыш-яшәү шартларын

киңәйтәләр. Әлбәттә, илкүләм мәдәниятнең йогынтысы зуррак була, ә менә катнаш никахларда ике мәдәниятнең көн саен һәм күп мәртәбәләр очрашуы ике телле гаиләләрне барлыкка китерә. Ягъни татар ислам җәмгыяте әгъзалары үзләренең кем булуларын онытмыйлар – лингвистик һәм мәдәни мирасларына, диненә һәм дә төп халыкны тәшкил иткән финнәрнең шушы ук кыйммәтләренә нигезләп, балансны югалтмыйлар.

### Бай һәм тере тел

Фин татарларының ана теле татар теленең бер диалекты булып тора, дөресрәге ул аның көнбатыш, мишәр диалекты. Татар теле төрки телләрнең кыпчак тармагына карый, гаиләдә һәм җәмгыятьтә шушы тел кулланылу сәбәпле, балалар аны беренче тел буларак үзләштерәләр. Ата һәм ана гына түгел, әбибабайлар һәм туганнар җаваплылыгына нигезләнгән бала тәрбиясе һәр нәрсәнең башлангыч ноктасын тәшкил итә. Телгә өйрәтү татар ислам җәмгыяте тарафыннан оештырылган ял көннәре, балалар уен төркемнәре, шулай ук көз, яз һәм җәй айларында оештырылган ана теле курслары аша тормышка ашырыла. Яшьләр җәмгыять тарафыннан оештырылган мондый чараларда актив катнашалар. Мисал итеп мәдәни чаралардан хор һәм театр тамашаларында катнашуны китерергә була. Гомумән алганда мондый аралашулар, гаилә һәм туганнар арасындагы тыгыз бәйләнешләр ана телен куллануга иң яхшы пропаганда ысулы булып тора. Гадәттә ана теле укытучыларын татар ислам җәмгыяте үзеннән билгели, ә элегрәк, аларны өстәмә ресурс буларак, Төркиядән чакыралар иде. Җәмгыятьнең төрек һәм фин телләренең латин графикасы белән язылышына нигезләнгән үз язу ысулы бар. Ана телен өйрәнү, гомумән, милли үзенчәлекләрне саклап калуның нигезен тәшкил итә.

Фин теленең азчылык теленә ясаган зур йогынтысына карамастан, татар җәмгыяте ачык һәм хәяти әһәмиятле лингвистик үзәк бурычын лаеклы үти. Россия Федерациясе составындагы Татарстан Республикасы һәм аның башкаласы булган Казан шәһәренең мәдәни түгәрәкләре белән булган мәдәни элемтәләр дә телне саклауга зур ярдәм итә. Йөз ел дәвамында телебез бер үк вакытта төрек һәм заманча Казан татар теле белән баетылды. Халыкара бәйләнешләрне ныгыта барып, татар җәмгыяте дөньядагы бөтен татар җәмгыятьләре белән элемтәләр корды. Мисал өчен, Швеция, Эстония, Төркия, Австралия һәм Америка Кушма Штатларындагы татар җәмгыятьләре белән булган элемтәләр ана телен куллану мөмкинлекләрен тагын да киңәйтәләр.

Финляндия татар җәмгыяте бай һәм күп төрле мәдәни мираска ия. Халык җырлары һәм музыкасы татар ислам җәмгыяте әгъзаларын мәдәни һәм башка уртак чараларга берләштереп торалар. Шулай ук татар әдәбияты классикларының әсәрләренә нигезләнгән театраль тамашалар да бик популяр. Фин татарлары

үз әдәби әсәрләрен дә булдырдылар. Җырлар, шигырьләр, дини хезмәтләр һәрвакыт газетада һәм «Мәхәллә хәбәрләре» журналында бастырыла килә.

**Җәмгыятьнең бердәмлек рухы**

Аз санлы җәмгыятьләр өчен дин иң мөһим мәсьәләләрдән санала. Ул – кешеләрне рухи инанулары буенча туплый торган ресурс та. Татарлар ислам динен X гасырда исламны кабул иткән һәм Идел буенда яшәгән борынгы болгар бабаларыннан мирас итеп алганнар. Фин мөселман җәмгыяте (1963 елдан Финляндия ислам җәмгыяте) 1923 елда гамәлгә кергән беренче Дини азатлык кануны нигезендә 1925 елда дини җәмгыятьләр реестрына кертелә. Европада Финляндия – Ислам җәмгыятен рәсми рәвештә таныган беренче ил булып тора. 1915 елда ук оешкан Хельсинки мөселман хәйрия җәмгыяте (Helsingin musulmaanien hyvantekevaisyysyhdistys) дә илдә татар халкын берләштерүгә һәм аның көндәлек мәсьәләләрен чишүгә ярдәм итә.

Ислам җәмгыяте ел дәвамында (аеруча язгы лагерьларда) мәктәп укучыларының дини тәрбия алуы турында кайгырта. Җәмгыять имамнары дини тәрбияне татар телендә бирәләр. 1960 елның урталарыннан бирле җәмгыять имамнарны Төркиядән чакыра иде. Советлар Берлеге таркалганнан соң намаз укыту, вәгазь сөйләү, никах һәм башка дини чаралар өчен имамнарны Россия Федерациясенең татар җәмгыятьләреннән чакыра башладылар. Имам сайлау таләпләре татар телен белүне, яңа шартларга һәм фин җәмгыятенә җайлаша алуны үз эченә ала. Җәмгыять әгъзалары ирекле рәвештә җәмгыятьнең төрле вазифаларын да үтиләр.

Ислам җәмгыяте дини оешма гына түгел, ул – үз карамагындагы мәдәни һәм спорт клубларына һәм дә мәдәни мираска матди һәм мәгънәви ярдәм итүче унитар, лингвистик һәм мәдәни җәмгыять тә. «Финляндия төркиләре берлеге – ФТБ» мәдәни җәмгыяте – 1935 елда, ә аның «Йолдыз» исемле спорт клубы 1945 елда корылган. 1948–1969 еллар арасында Хельсинкида татарларның төрки телдә башлангыч белем бирү мәктәбе эшләде. Анда, фин башлангыч мәктәбенең уку программасыннан тыш, татар теле, дин һәм төрки халыкларның тарихы дәресләре укытыла иде. Кыска бер дәвер эчендә анда төрек теле дә укытылды. Мәктәпкә Хельсинки шәһәре һәм татар җәмәгатьчелеге тарафыннан матди ярдәм күрсәтелде. Моннан тыш, Хельсинки, Тампере һәм Турку шәһәрләрендә җәмгыятьнең актив әгъзалары тарафыннан корылган башка мәдәни оешмалар да эшләп киләләр.

Җәмгыятьнең Хельсинки үзәгендә 1960 елда төзелеп беткән һәм җәмгыятьнең үз көчемсез милеге булган бинасында мәчет, җыелышлар залы, аш пешерү бүлмәсе, җәмәгать офисы, клуб, укытучылар бүлмәсе, кечкенә китапханә, ике укыту бүлмәсе һәм башка оешмаларның җыелыш бүлмәсе урнашкан. Җәмгыять милләттәшләребезнең

мәңгелек урыны – Хельсинки белән Турку шәһәрендәге зиратларны тәртиптә тотуга да зур игътибар бирә.

### Мәдәни үзенчәлекләр

Мөһим дини бәйрәмнәр һәм кичке чаралар ислам җәмгыяте әгъзаларын – аралашуга, уртак бәйрәмнәргә, күңел ачуга туплыйлар һәм, җәйге лагерь кысаларында оештырылган Сабантуй кебек, милли фестивальләргә җыялар.

Гадәти мәҗлесләр һәм милли ризыклар татар көнкүрешендә мөһим урын алып тора. Араларында камыр ризыкларыннан пәрәмәч һәм ашлардан шурпа да бар. Мәдәни җәмәгатьчелек милли ризыклар рецептларыннан фин һәм татар телендә аш-су китабы бастырып чыгарды.

Өлкәннәр турында кайгырту да татарларның социаль мәдәниятенең үзенчәлеге булып тора. Җәмгыять тарафыннан оештырылган атналык җыеннар – лаеклы ялда булучылар һәм картлар өчен бер-берсен күреп, аралашып ял итү чыганагы.

Икенче яктан, бергәләп хобби белән шөгыльләнер өчен тудырылган мөмкинлекләр, спорт чаралары яшьләрне тупларга ярдәм итә. Кышкы ял вакытында спорт клубы мәктәп балалары һәм аларның гаиләләре өчен кышкы лагерьлар оештыра. Кайбер милләттешләребез теннис һәм гольф белән шөгыльләнәләр. Спорт клубының «Йолдыз» футбол командасы, Хельсинки дивизионыннан тыш, Финляндиядәге яһүди (Маккаби) һәм гарәп (Сайкус) футболчылары белән дустанә матчларда катнаша. Эстония татар җәмәгыятенең футбол командасы Финляндияга килеп китте, ә «Йолдыз», дустанә ярышларда катнашу өчен, Алжир, Төркия һәм Татарстанда булып кайтты.

### Интеграция

Соңгы елларда яңа социаль күренешләр һәм интернациональләшү йогынтысы астында ислам җәмгыятьнең төзелеше шактый үзгәрешләр кичерде. Милләттәшләребезнең җирле халык белән тыгыз аралашуы ике телле һәм ике мәдәниятле гаиләләрнең барлыкка килүенә китерде. Мондый гаиләләрдә азчылыкның телен һәм мәдәниятен саклап калу өчен җәмгыять тарафыннан күп көч таләп ителә. Өлкән буын вәкилләре, еш кына, финнәр җәмгыятендә уңышлы булу өчен башкаларга караганда күбрәк һәм яхшырак эшләргә кирәклеген ассызыклыйлар. Алар, үз туган илләрендәге мәгариф системасын югары бәяләп, татар балаларына Финляндиядә дә яхшы белем бирү мөмкинлеге өчен бизнес өлкәсендәге эшмәкәрләрнең инвестиция ясавына ирештеләр. Җәмгыять әгъзалары Финляндиянең милли, мәдәни һәм икътисади үсешенә дә үз өлешләрен кертәләр.

Татар ислам җәмгыятенең яңа килүче иммигрантларга сүзе шушы: азчылыклар үз телләрен, диннәрен һәм мәдәни мирасын сакларга тырышырга тиешләр. Шул ук вакытта Финляндия җәмгыятенә җайлашу һәм аның кануннарына буйсыну да зарур. Фин телен өйрәнү – белем алу

һәм эшкә урнашуның мөһим аспекты булуы да табигый. Нәтиҗәле интеграция эзлекле һәм дәвамлы тырышлыкларны таләп итә. Үз милли рухи һәм матди мирасларына өстәмә буларак, кешеләр бай мәдәни мохиттән көч алырга тиешләр. Азчылыкларның җирле халык телен белүләре һәм киң кырлы, дөньяви белемнәре үзләре яшәгән илдә мәдәни һәм сәүдә мөнәсәбәтләрендә кулланыла торган ресурс булып санала.

## Хокукый мөмкинлекләр

Финляндия ислам җәмгыяте үз эшчәнлеген фин татарларының вәкилле органы буларак алып бара. Аның шурасы рәистән, биш әгъзадан, аларның өч урынбасарыннан һәм җәмгыять имамыннан корыла. Җәмгыять милли һәм халыкара дәрәҗәдә Бөтендөнья татар конгрессы кебек үк хокукларга ия. Җәмгыять шурасы вәкилләре Финляндия ил башлыклары катнашындагы дәүләткүләм рәсми визитларда һәм сәүдә миссияләрендә катнаша алалар.

Фин татарлары дини һәм мәдәниятара диалогларда актив катнаша, ислам җәмгыяте җитәкчелеге Финляндия хөкүмәте билгели торган Этник мөнәсәбәтләр консультатив советында (ETNO), Финляндиянең кулланышта булган кече телләр бюросында (FIBLUL), Финляндиянең диннәрара милли хезмәттәшлек форумында (CORE) һәм башка мөһим очрашуларда катнашу мөмкинлегенә ия.

**Әдәбият**

*Muazzez Baibulat:* Tampereen Islamilainen Seurakunta: juuret ja historia. Jyvaskyla, 2004.

*Kadriye Bedretdin* (ed.): Tugan tel. Kirjoituksia Suomen tataareista. Finnish Publications of the Finnish Oriental Society, No. 39. Jyvaskyla, 2011.

*Okan Daher:* Orthographical traditions among the Tatar minority in Finland. In Juha Janhunen & Volker Rybatzki (eds.): Writing in the Altaic World. Studia Orientalia 87, pp. 44–48. Helsinki, 1999.

*Harry Halen:* Suomen tataarit. In Markku Loytonen and Laura Kolbe (eds.): Suomi. Maa, kansa, kulttuurit. Finnish Literature Society Publication No. 753. Jyvaskyla, 1999.

*Tuomo Hirvonen* (ed.): Suomen Islam-seurakunnan veteraaniteos. Finnish Islamic Congregation. Jyvaskyla, 2006.

*Kari Karvonen* (ed.): Suomen Islam-seurakunta 1925–1975. Finnish Islamic Congregation. Helsinki, 1975.

*Antero Leitzinger:* Suomen tataarit; vuosina 1868–1944 muodostuneen muslimiyhteison menestystarina. Tampere, 2006.

Tatarica: studia in honorem Ymar Daher, anno MCMLXX sexagenario. Edendum curavit Abdulla Tukai Cultural Society, ed. Lauri Kotiniemi. Vammala, 1987.

***Окан Таһир Гомәр улы,***
*Хельсинки университетының татар теле*
*һәм мәдәнияте дәресләре лекторы,*
*Финляндия ислам татар җәмгыятенең*
*шәрәфле президенты*